**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «02» ноябреннән № 434

2021 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2009 елның 3 октябрендәге 888нче номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган партнерлыгының 2021 елның IV кварталына торак биналарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча Эксперт-консультация советы тикшеренүләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасында халыкны сыйфатлы торак белән һәм торак коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл җирендә яшәүче гражданнарның, яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясен 2021 елның IV

кварталына – федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 30 905 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов